Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XX-4**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 24 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 4 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында тапшыру турында килешүләр төзү Тәртибен раслау хакында" 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-4 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Башкарма комитеты тәкъдимен кабул итәргә:

1.1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына:

җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда, җирлек чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен кире алганда объектлар төзелешенә (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан гайре), аларны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамәләр бирү;

1.2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына:

муниципаль ихтыяҗлар өчен җирлек чикләрендә җирләрне резервлау, җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен әлеге карарга 1,2 нче кушымталарга ярашлы рәвештә тапшыру турында, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын күздә тотып. килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиясенә һәм экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2017 елның 24 июлендәге
XX-4 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

**КИЛЕШҮ**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның ____ ____________

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты үзенең җитәкчесе __________________йөзендә, Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә эш итүче, алга таба “район Башкарма комитеты” дип аталучы бер яктан һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты үзенең җитәкчесе _______________йөзендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә эш итүче, алга таба ”җирлек Башкарма комитеты” дип аталучы икенче яктан әлеге Килешүне түбәндәгеләр хакында төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

Әлеге Килешүнең предметы булып җирлек Башкарма комитеты тарафыннан район Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру тора:

җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда, җирлек чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен кире алганда объектлар төзелешенә (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан гайре), аларны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамәләр бирү.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Җирлек Башкарма комитеты район Башкарма комитетына бирергә тиеш:

әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чараларын (алга таба - вәкаләтләр);

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны.

2.2. Җирлек Башкарма комитеты хокуклы:

әлеге Килешүнең 4.1-4.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә район Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрнең үтәлешен, шулай ук бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны тикшереп торуны башкарырга;

әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүматны район Башкарма комитетыннан алырга.

2.3. Район Башкарма комитеты бурычлы:

законнар таләпләре нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга, шул исәптән җирлек Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

җирлек Башкарма комитетына вәкаләтләрнең үтәлеше турында квартал саен хисаплар, шулай ук аерым гарызнамәләр буенча Килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат тапшырырга.

2.4. Район Башкарма комитеты хокуклы:

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек Башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алырга һәм кулланырга;

җирлек Башкарма комитетыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә законнар нигезендә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдаланырга.

**3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе**

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары җирлек бюджетыннан район бюджетына бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары күләме әлеге Килешүгә кушымта нигезендә билгеләнә һәм елына ____________________ сум күләмендә билгеләнә.

3.3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары җирлек бюджетыннан район бюджетына ай саен тигез өлешләр белән күчерелә.

3.4. Район Башкарма комитеты финанс средстволарын максатчан файдаланмаган очракта, алар җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча ун көн эчендә җирлек бюджетына кайтарылырга тиеш.

**4. Вәкаләтләрне үтәүгә контроль**

4.1. Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында район Башкарма комитетыннан кирәкле мәгълүматны соратып ала. Район Башкарма комитеты җирлек Башкарма комитеты соравы буенча сорала торган мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

4.2. Хисапларның формасы һәм аларны бирү тәртибе җирлек Башкарма комитетының хокукый актлары белән билгеләнә.

4.3. Тапшырылган финанс средстволарын тотуны тикшереп тору Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының контроль-хисап палатасы тарафыннан тышкы муниципаль финанс контроле рәвешендә, шул исәптән җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча да, гамәлгә ашырыла.

**5. Килешүнең гамәлдә булу вакыты**

5.1. Килешү Яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә һәм 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

5.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5.3. Килешү 2018 елга озайтылган дип санала, әгәр Якларның берсе дә аны өзү турында әлеге Килешүнең 5.1 пунктында каралган срок тәмамланырга 30 көннән дә соңга калмыйча белдермәсә.

**6. Килешүне вакытыннан алда туктатуга нигезләр һәм аның тәртибе**

6.1. Әлеге Килешүнең гамәле вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

бер яклы тәртиптә, Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

6.2. Әлеге килешүне өзү турында хәбәрнамә икенче якка, аның гамәлдә булу датасына кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә җибәрелә.

6.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, район Башкарма комитеты җирлек Башкарма комитетына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтара.

**7. Якларның җаваплылыгы**

7.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

7.2. Әлеге килешү буенча үз йөкләмәләренең бер өлешен үтәмәгән өчен гаепле як икенче якка әлеге килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

7.3. Штраф түләү әлеге килешү буенча йөкләмәләрне киләчәктә үтәүдән азат итми.

**8 маддә. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе**

8.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә.

8.2. Бәхәсне сөйләшүләр уздыру яки килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

**9. Йомгаклау нигезләмәләре**

9.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм өстәмә килешү белән язма рәвештә рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9.2. Килешү Якларның һәркайсы өчен бердәй юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелгән.

**10. Якларның имзалары**

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе<br><br>______________ ____________ | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе<br><br>_______________ ___________ |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Башкарма
комитетына Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге
Башкарма комитетының Татарстан
Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Балык Бистәсе
шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге
мәсьәләләрен хәл итү буенча
вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру
турында
Килешүгә кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге бюджетыннан тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләмен билгеләү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсендә каралган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бирелә торган бюджетара трансфертлар күләмен билгеләү тәртибен тәгаенли:

җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда, җирлек чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен кире алганда объектлар төзелешенә (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан гайре), аларны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамәләр бирү.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге бюджетыннан әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләмен исәпләгәндә, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди-техник тәэмин итү чаралары исәпкә алына.

Бюджетара трансфертларның еллык күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$S_{мбт} = S_{бум} \times 2$ , биредә

$S_{мбт}$ – тапшырыла торган вәкаләтләрне тәэмин итүгә муниципаль район өчен бюджетара трансфертлар күләме;

$S_{бум}$ - А4 форматындагы кәгазьнең 1 төргәге бәясе (250 сум);

2 - әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру

өчен елына кәгазьләрне төргәкләүнең кирәкле күләмен исәпкә ала торган коэффициент.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда бюджетара трансфертлар күчерү гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2017 елның 24 июлендәге
XX-4 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешү**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның ____ ___________

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы үзенең җитәкчесе __________________йөзендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы турындагы Нигезләмә нигезендә эш итүче, алга таба “Палата” дип аталучы бер яктан һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты үзенең җитәкчесе ______________йөзендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә эш итүче, алга таба ”җирлек Башкарма комитеты” дип аталучы икенче яктан, бергә “яклар” дип аталучылар әлеге Килешүне түбәндәгеләр хакында төзеделәр:

**1. Килешү предметы**

Әлеге Килешүнең предметы булып җирлек Башкарма комитеты тарафыннан Палатага түбәндәге вәкаләтләрне тапшыру тора:

муниципаль ихтыяҗлар өчен җирлек чикләрендә җирләрне резервлау,
җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру.

**2. Якларның хокуклары һәм бурычлары**

2.1. Җирлек Башкарма комитеты Палатага бирергә тиеш:

әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чараларын (алга таба - вәкаләтләр);

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны.

2.2. Исполнительный комитет поселения имеет право:

осуществлять контроль за исполнением Палатой полномочий, а также за целевым использованием предоставленных финансовых средств, в порядке, определенном пунктами 4.1-4.3 настоящего Соглашения;

получать от Палаты информацию, касающуюся предмета настоящего Соглашения.

2.2. Җирлек Башкарма комитеты хокуклы:

әлеге Килешүнең 4.1-4.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә Палата тарафыннан вәкаләтләрнең үтәлешен, шулай ук бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны тикшереп торуны башкарырга;

әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүматны Палатадан алырга.

2.3. Палата бурычлы:

законнар таләпләре нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга, шул исәптән җирлек Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

җирлек Башкарма комитетына вәкаләтләрнең үтәлеше турында квартал саен хисаплар, шулай ук аерым гарызнамәләр буенча Килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат тапшырырга.

2.4. Палата хокуклы:

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек Башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алырга һәм кулланырга;

җирлек Башкарма комитетыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә законнар нигезендә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдаланырга.

**3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе**

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары җирлек бюджетыннан район бюджетына бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары күләме әлеге Килешүгә кушымта нигезендә билгеләнә һәм елына _____________________ сум күләмендә билгеләнә.

3.3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары җирлек бюджетыннан район бюджетына ай саен тигез өлешләр белән күчерелә.

3.4. Палата финанс средстволарын максатчан файдаланмаган очракта, алар җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча ун көн эчендә җирлек бюджетына кайтарылырга тиеш.

**4. Вәкаләтләрне үтәүгә контроль**

4.1. Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында Палатадан кирәкле мәгълүматны соратып ала. Палата җирлек Башкарма комитеты соравы буенча сорала торган мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

4.2. Хисапларның формасы һәм аларны бирү тәртибе җирлек Башкарма комитетының хокукый актлары белән билгеләнә.

4.3. Тапшырылган финанс средстволарын тотуны тикшереп тору Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының контроль-хисап палатасы тарафыннан тышкы муниципаль финанс контроле рәвешендә, шул исәптән җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча да, гамәлгә ашырыла

## 5. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

5.1. Килешү Яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә һәм 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

5.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5.3. Килешү 2018 елга озайтылган дип санала, әгәр Якларның берсе дә аны өзү турында әлеге Килешүнең 5.1 пунктында каралган срок тәмамланырга 30 көннән дә соңга калмыйча белдермәсә.

## 6. Килешүне вакытыннан алда туктатуга нигезләр һәм аның тәртибе

6.1. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

бер яклы тәртиптә, Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

6.2. Әлеге килешүне өзү турында хәбәрнамә икенче якка, аның гамәлдә булу датасына кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә җибәрелә.

6.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, Палата җирлек Башкарма комитетына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтара.

## 7. Якларның җаваплылыгы

7.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

7.2. Әлеге килешү буенча үз йөкләмәләренең бер өлешен үтәмәгән өчен гаепле як икенче якка әлеге килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

7.3. Штраф түләү әлеге килешү буенча йөкләмәләрне киләчәктә үтәүдән азат итми.

**8 маддә. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе**

8.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә.

8.2. Бәхәсне сөйләшүләр уздыру яки килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

**9. Йомгаклау нигезләмәләре**

9.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм өстәмә килешү белән язма рәвештә рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9.2. Килешү Якларның һәркайсы өчен бердәй юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелгән.

**10. Якларның имзалары**

<table>
<tr><td>Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе<br><br>______________ ____________</td><td>Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе<br><br>_______________ ___________</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан
Республикасы Балык Бистәсе муниципаль
районының Балык Бистәсе шәһәр җирлеге
Башкарма комитетының Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең җирле
әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча
вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру
турында Килешүгә кушымта

**Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына Балык Бистәсе шәһәр җирлеге бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар күләмен билгеләү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге бюджетыннан “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне

оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсендә каралган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләмен билгеләү тәртибен тәгаенли:

җирлек чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлау, җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге бюджетыннан әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләмен исәпләгәндә, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди-техник тәэмин итү чаралары исәпкә алына.

Бюджетара трансфертларның еллык күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

Sмбт= Sбум х 2 , биредә

Sмбт – тапшырыла торган вәкаләтләрне тәэмин итүгә муниципаль район өчен бюджетара трансфертлар күләме;

Sбум - А4 форматындагы кәгазьнең 1 төргәге бәясе (250 сум);

2 - әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен елына кәгазьләрне төргәкләүнең кирәкле күләмен исәпкә ала торган коэффициент.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда бюджетара трансфертлар күчерү гамәлгә ашырыла.